**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ СТАРОУТЯМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423105,Черемшанский район, с.Старый Утямыш, ул.Мусы Джалиля, дом 52

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ИСКЕ ҮТӘМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423105,Чирмешән районы Иске Үтәмеш авылы, Муса Җәлил урамы, 52 нче йорт

тел./факс 8-84396-2-37-16 email: Sut.Cmn2@tatar.ru

**14.10.2020** **№7**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 79 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарының 1 өлешендәге 3 абзацын (2018 елның 16 ноябрендәге 94 номерлы үзгәрешләр белән) бәян итәргә:

1.1. «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 11 498 сум тәшкил итә»;

1.2. «Зnче кушымтаны «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләме» яңа редакциядә бәян итәргә, кушымта нигезендә.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
Башлыгы, Совет Рәисе Р.С.Мингулов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
Советының 2020 елның
14 октябрендәге
7 номерлы карарына
3 нче кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен
даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының
айлык акчалата түләү күләме

| Вазыйфаларның атамалары | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 15759,00 |